**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы  Килдураз  авыл җирлегенең  Иске Лашчы  авылында гражданнар җыены карары**

20 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ  номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Килдураз  авыл җирлегенең  Иске Лашчы  авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Килдураз  авыл җирлегенең  Иске Лашчы  авылында территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия   балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 1000 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге  җирле  мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- ремонт, коймалар кору, традицион җирләү урыннарын төзекләндерү;

- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны карап тоту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);»

3. Җыен нәтиҗәләрен Килдураз  авыл җирлегенең  Иске Лашчы  авылында авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Килдураз авыл җирлеге башлыгы _________ З.З.Әхәтов

Гражданнар җыены секретаре _________ Л.И.Шәфигуллина